**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№1** **09.01.2020 ел**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне :

а) Алан-Бәксәр авылында 1 нче чишмәне төзекләндерү;

б) Алан-Бәксәр авылы урам юлларын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;

в) Алан-Бәксәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам яктыртуы өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру)
башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?»

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2019 елның 08 ноябрендә 14 сәг.00 мин. һәм 2019 елның 08 ноябрендә 16 сәг.00 мин. этаплап уздырылган гражданнар җыеннарының нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 225 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 126 кеше, бу 56 % тәшкил итә.

гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары тавыш бирү нәтиҗәләре буенча түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 126 кеше тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл жирлеге Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

а) Алан-Бәксәр авылында 1 нче чишмәне төзекләндерү;

б) Алан-Бәксәр авылы урам юлларын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;

в) Алан-Бәксәр авылында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту (яктырткычлар, фотоэлементлар, исәпкә алу приборлары, идарә щиты, урам яктыртуы өчен ЛЭП сатып алу һәм урнаштыру)

башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?» соравы буенча карарны уңай кабул ителде дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтының авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башлыгы: З.Р.Гарифуллина